**Республика Татарстан**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

---

## Постановление

«22» август, 2023 ел                                                                                    № 1335

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Сафин Фәйзрахман Әхмәтҗан улы исемендәге Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертү һәм аны яңа редакциядә раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 13.3 статьясы, «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы җирле үзидарәсенең ведомство органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2018 елның 24 июлендәге 150 номерлы карары 2.2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Сафин Фәйзрахман Әхмәтҗан улы исемендәге Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе Уставын китерү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Сафин Фәйзрахман Әхмәтҗан улы исемендәге Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставына үзгәреш кертергә (кушымтада бирелә).

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Сафин Фәйзрахман Әхмәтҗан улы исемендәге Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры М. Г. Хәсәновага Уставны яңа редакциядә дәүләт теркәвенә алганда, законда билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгать итүче булырга;

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы сайтында әлеге карарны бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары З.Ш. Мөхәммәтгәрәевага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитетының җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы                                                                Р. Р. Шәйхетдинов